ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 475-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 475-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2118-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында**

**1 статья**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге $227^1$ статьясы нигезендә 2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны 2,163гә тигез итеп билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм физик затлар керемнәренә салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче көненнән дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

## АҢЛАТМА

«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба - закон проекты) Россия Федерациясе Салым кодексының 2271 статьясындагы 3 пункты нигезендә эшләнгән.

Закон проекты тарафыннан төбәк коэффициентын республика территориясендә эшчәнлекләрен патент нигезендә физик һәм юридик затларга ялланып гамәлгә ашыручы чит ил гражданнары физик затлары керемнәренә салым буенча билгеләп куелган аванс түләүләренә 2,163 итеп билгеләү күздә тотыла. 2023 елга төбәк коэффициенты 2,08 күләмендә билгеләнгән.

Коэффициентны билгеләү 2024 елга чит илдән килеп эшләүчеләрнең фаразланган уртача айлык хезмәт хакларыннан (45 328,0 сум) физик затлар кеременә салына торган 13% салым нисбәтенә, шулай ук коэффициент-дефляторны (2,27) − 2 724 сум исәпкә алып, салым буенча билгеләп куелган аванс түләве күләменә (1 200,0 сум) базалаша (45 328,0 × 13%) / (1 200,0 × 2,27) = 2,163.

Төбәк коэффициенты күләме патентның бәясен билгели. Татарстан Республикасында патентның фаразланган бәясе 2024 елда 5 892 сум тәшкил итәчәк (2023 елда - 5 666 сум).

Кертелә торган коэффициент чит илдән килеп эшләүчеләрнең салымнары керүне тәэмин итәчәк, юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга мигрантларны хезмәт эшчәнлегенә патентлар нигезендә легаль җәлеп итү мөмкинлеген бирү хисабына хезмәт хакын «күләгәдә» калдыруны кисәтүгә ярдәм итәчәк. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: республика территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы чит ил гражданнарының керемнәренә салым буенча алына торган түләүләрнең бөтен суммасы тулысынча республика бюджетына күчерелә.

Чит ил гражданнарының физик затлары керемнәренә салым суммасы, 2023 елның 1 сентябренә торышы буенча республика бюджетына кергән аванс түләве рәвешендә, 1 млрд. 400 млн. сум тәшкил иткән.

**«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары региональ үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары региональ үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.